# Кояшлы әсәрләр

Җир йөзендә күңел дөньясы тәңгәл булган ике кеше бармы икән? Юктыр. Һәр кеше — үзе бер галәм. Шагыйрь җанлы шәхес бигрәк тә. Әйтик, Фирая Зыятдинова әнә үзе турында нәрсә ди:

Мин үземә сыймыйм,
Дәрья булып ташам,
Җанны җырга салып,
Кешеләргә дәшәм…

Җанны җырга тиңләү, әгәр ныклап уйлап карасаң, дөрес тә. Ник дигәндә, җыр ул — җанның борчылуы, талпынуы, моңсулануы, шатлануы, әсәрләнүе. Шагыйрьләр бу дөньяга әнә шундый сәләт белән туа. Моны башкача аңлатып булмый.

Фирая Зыятдинова да карап торышка гадинең дә гадие, ниндидер аерым билгеләре белән башка хатын-кызлардан әллә ни аерылып тормаучы, үтә тыйнак, җыйнак, бик пөхтә иде. Артыгын сөйләшмәс, кемнәрдер кебек шау-шу тудырмас, кычкырып көлмәс. Күпчелек вакытында уйчан булыр иде. Аның шагыйрьлегенең күзгә бәреп торган билгесе әнә шул тыйнак уйчанлыгы иде булса кирәк.

Бүтән нәрсә миннән эзләмәгез:
Мин шигырьдән торам.
Кояш тулы күңелемнең йортын
Мин шигырьдән корам.

Иҗат кешесенең төп кыйммәтле сыйфатларыннан берсе — аның хакыйкатькә тугрылыгы. Чын шагыйрь башкача була да алмый. Укучы аңардан бары тик дөрес хәл-әхвәлләр, дөрес хис-кичерешләр бәян ителүен генә көтә. Ф. Зыятдинова да үзенең бу мәсьәләгә карашын кистереп әйтеп куя:

Ялган белән чынлык арасына
Хәйлә күперләре салалмыйм.

Яратыгыз мине шушы килеш —
Мин үземә каршы баралмыйм.

Димәк, ярымъялган, ярымчынлык шигырьләрдә урын ала алмый. Шагыйрьне хакыйкать тарафдары буларак кына кабул итеп була. Киресенчә булганда, шигырьләр үзләренең изге вазифаларын үти алмый.

Чынбарлык ул шундый!
Тәнгә генә түгел,
Сала тора җанга яралар.
Мин бәхетле,
Кагылу-сугылудан
Хет бер җанны алсам аралап.

Әдәби әсәрнең хасияте дә шунда: ул автор тарафыннан ялгыз тудырыла, аны кабул итүче дә күпчелек очракта берүзе була. Шул рәвешле, шагыйрь белән укучы кара-каршы кала. Бер кешенең җанын дәвалау — үзе генә дә зур эш, әмма сүз йөзләрчә-меңнәрчә яралы йөрәкләргә шифа бирү турында барырга мөмкин. Бу — хис чынлыгы, караш ныклыгы, ышанычлы иман булганда гына мөмкин.

Фирая Зыятдинова шигъриятенә чичәнлек тә хас. Хикмәтле сүз әйтергә омтылу, шуны әйтә белү — шагыйрьлекнең зур билгесе. Аңардан байтак хикмәтле фикерләр табарга мөмкин.

Кеше кайгысына кайгыру ул
Әллә ни зур егетлек түгел.
Кеше шатлыгына кайгырма син —
Үзеннән дә ныграк сөенә бел!

* * *

Кузгатмагыз иске яраларны —
Кузгалырга тора яңалары...

Аның хикмәтле сүзләрендә — тормыш, яшәү фәлсәфәсе, җан һәм күңел өчен кануннар җыелмасы. Мондый фикерләрне яшәүнең бөтен катлаулылыкларын үз тәҗрибәсендә белгән кеше генә әйтә ала.

Фирая ханымның шигырьләрен кояшлы әсәрләр дип атарга мөмкин. Әлеге күк җисеме аның өчен шулкадәр якын, үз, шул яшәү чыганагы ярдәмендә шагыйрә нинди генә халәтне, хисләрне белдерми. Кояш аның күңел тирбәлешләренә карап, төрле ассоциацияләр тудырырга ярдәм итә.

Күңелемә ак өметләр тулган,
Кояш — минем дустым.

Биредә лирик геройның күңел дөньясы түгәрәк, ул — яшәүнең рәхәтен, тәмен тоючы, чын мәгънәсендә бәхетле зат.

Дөньяга дәшеп бага ул,
Кояшка дәшеп бага...

Кеше күңеленең төрле вакытта төрлечә булуы, кояшның шуңа бәйле рәвештә сыйфатларын үзгәртүе җәһәтеннән караганда, «Яр астында кояш баеды» шигыре үзенә бер махсус әсәр булып туган. Шигырьдә әлеге күренеш чираттагы бер көннең төшеп югалуы дип бәяләнә. Монысы — вакытның мәңге дәвамлы булуына ишарә. Әмма халыкта, аерылулар булмаса, кавышулар да булмас иде, дигән һәм диалектиканың мәңгелек канунын гап-гади итеп аңлаткан гыйбарә бар. Шагыйрә дә кояш баюына бәйләнешле әнә шул уйлануларын иртәгесе көннең, киләчәкнең өметле булырына ышанып тәмамлый.

Чык күзендә тагын җемелдәргә,
Юарга дип җирдән кайгыны,
Ялт иттереп иртән чыгарга дип,
Яр астында кояш баеды...

Кояш Ф. Зыятдинова шигъриятенең үзәгендә тора. Аның бу дөньяда иң ышанычлы таянычы да — Кояш. Биредә «Кояш» сүзе күпмәгънәлелек белән игътибарны җәлеп итә. Ул яраткан кешесе дә, Иманы да, нинди дер бер аерым ышанычы да булырга мөмкин. Әмма ул бар һәм кирәк вакытта аңа рухи таяныч булып хезмәт итә.

Бүтәннәрне дә ул Кояшлы булырга, аның тугрылыгын, хыянәтсез булуын тоярга, күңелдә барлыкка килгән юшкыннардан аның ярдәмендә котылырга чакыра:

Син Кояшка эндәш, чәчәкләргә —
Җир җылысын кабат тоярсың.
Кояш күргән гөл сабагы төсле,
Күңелеңдә өмет уянсын.

Күрегез, бик тә нәзберек, нечкә күңелле, әмма шул нәфис, сизелер-сизелмәс тирбәлешләрне Галәм үлчәмнәренә куеп уйлаучы булган икән бит безнең шагыйрәбез Фирая Зыятдинова! Юкка гына шагыйрьләр «мин —әсәрләремдә» димиләр икән. Тормышта гап-гади генә, мөлаем гына булган Фирая ханым шигырьләрендә әнә нинди киң колачлы,

кайнар хисле, хикмәтле сүзле каләм әһеле булган икән. Аның һәрбер әсәре үзенең «мин»е аша дөньяны, кешелекне ачуга багышланган. Ул тормышка, тирә-якка җайлашып яшәүгә каршы, үз-үзе булып калу — аның өчен табигый халәт. Аның менә бу әсәрен (автор аңа исем куймаган, әмма аны «Үз-үземә кайттым» дип атарга мөмкин) татар әдәбиятындагы шигъри энҗеләрнең берсе дип санап булыр иде:

Мин тынычлык таптым!
Тик...
Үземне югалттым...
Соң булганчы, диеп
Йөгерә-йөгерә,
Тыйгысызлыгыма —
Үз-үземә кайттым!

Әйе, вакытлыча гына яши торган бу дөньяда үз-үзеңне югалтудан да фаҗигалерәк нәрсә юктыр ул. Тик шунысы бар: иң әүвәл әнә шул югалтыр әйберне, ягъни үз-үзеңне булдырырга кирәк. Бик күпләр әнә шуны да таба алмыйча китеп бара. Табу һәм югалту. Болар — бербөтеннең капма-каршы яклары. Ф. Зыятдинова табигый, үз халәтеңне табарга һәм аңа һичкайчан хилафлык китермәскә өнди.

Үзе вафат булгач, Фирая ханымның бер шигыре күңелемдә гел яңгырап тора башлады:

Тормыш күкләрендә эз калдырып,
Йолдыз кебек атылып бер үткәч,
Нәрсә калыр бездән кешеләргә,
Ни диярләр икән без киткәч?

Һәр акыл иясе мондый сорауны куймый калмыйдыр. Күңелендә даими шигъри аһәңнәр яңгырап торган шәхес бигрәк тә. Фирая Зыятдинованың рухы борчылмаска мөмкин: ул фани дөньяда якты исем, нәфис шигърият, үзе турында матур фикерләр калдырып китте. Аның шигырьләре, аларга язылган матур җырлар көн саен яңгырап тора. Иманыбыз камил, халкыбызның аны һәр искә алуы рухына дога булып барып ирешер.

*ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН,*
*әдәбият галиме*

«Матур буласым килә»
китабыннан

1986

